


Бер гасыр дәвамында Татарстан Фәннәр академиясенен Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарлар яшәгән торле тобәкләргә фәнни экспедицияләр оештырып, халкыбызнын милли-мәдәни мирасын ойрәнv эшен дәвам итә.
Быел без 19–30 июньдә Мордовия Республикасында унике конлек фәнни сәфәрдә булдык. Барлыгы унбиш торак пунктта яшәvче татарларнын тел vзенчәлекләрен, халык авыз ижатын, эпиграфик һәйкәлләрен, традицион музыка мәдәниятен, татар халык сәнгате vрнәкләрен ойрәнv белән шогыльләндек. Һәр авылда безне якты йоз, ачык чырай белән каршы алып, кочләреннән килгәнчә ярдәм иттеләр. Без тагын бер кат халкыбызнын кунакчыллыгына һәм зыялылыгына инандык. Әлеге комплекслы фәнни экспедиция барышында Ромоданово районынын Ләбәжә (Алтары) авылында да булдык. Авыл халкы безне бик жылы каршы алды. Кояшлы матур жәй конендә яшеллеккә кvмелгән, балкып торган авылларында кунак итте. Торлебез торле юнәлештә эшләгәнлектән, йортларга кереп, авыл халкы белән аралашып, алдагы фәнни тикшеренvләребез очен бай материал тупладык. Авыл советы житәкчеләре, мәдәният йорты хезмәткәрләре, китапханәчеләр безне бик хормәтләп, авыллары, анда яшәvчеләр белән таныштырып йорделәр. Аларга без чиксез рәхмәтлебез!
Комплекслы экспедицияләр вакытында торле жирлекләрдә кием-салым, һонәрләр, азык-толек әзерләv рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да кvзәтvләр ясала. Шулай ук аларда эшләп килгән тобәкне ойрәнv музейлары да игьтибардан читтә калмый. Безгә шундыйларнын берсе – Ләбәжә авылы музее белән танышырга насыйп булды. Биредә безне халкы, vз авылынын тарихы, бvгенгесе һәм киләчәге очен жан атып яшәvче Наил  Хәйдәр улы Исхаков каршы алды. Ул безгә музей буенча экскурсия дә уздырды.
Музей мәктәпнен бер бvлмәсендә урнашкан. Ул 1995 елда мәктәп житәкчелеге инициативасы белән ачыла.  Музейны ачу һәм аны экспонатлар белән баету очен эзләнvчән, тынгы белмәс, искиткеч сәләтле, шул ук вакытта vжәт тә булган Исхаков Наил Хәйдәр улы зур тырышлык куя. Ул авыл, туган як тарихы буенча материалларны бортекләп жыя, бу эшкә мәктәп укучыларын, укытучыларны, ата-аналарны да жәлеп итә. Авылдашлары да ана зур ярдәм кvрсәтәләр.
Наил абый – укытучы, мәктәптә физика фәнен укыта, пенсия яшендә булуына карамастан, яраткан эшен ташламый, балаларга белем бирvен дәвам итә. 2019 елда «Беркем онытылмый, бернәрсә дә хәтердән жуелмый» проектында катнашып, Президент грантына ия була. Әлеге грант  исәбенә музейда ремонт эшләре башкарыла, андагы экспозицияләр тагын да баетыла.
Безгә торле музейлар, музей почмаклары белән танышырга туры килә, әйтергә кирәк, Ләбәжә авылы тобәкне ойрәнv музее гаять бай фондларга ия.
Музейнын бер бvлегендә Боек Ватан, Әфган, Чечня сугышларында катнашучылар турында материаллар, тобәк, авыл, мәктәп тарихы, кvмәк хужалык алдынгылары, авылнын танылган шәхесләре турында мәгълvмат урнаштырылган. Боек Ватан сугышы

каһарманнарынын, Әфганстан, Чечня дәһшәте аша vткәннәрнен, кайнар нокталарда булып, зур сынау юлы узганнарнын истәлеген кадерләп саклауга Наил Хәйдәр улы кvп коч куя. Ләбәжә авылыннан 16 егет Әфганстанда хезмәт итә. Ләкин шулардан Кадыйркаев Рафик Абдулла улы (Кызыл Йолдыз ордены белән бvләкләнгән) һәм Кузяев Монир Мансур улы vз интернациональ бурычларын vтәгәндә һәлак була. Аларга багышлап, якыннарына язылган хатлары, тәржемәи хәлләре урын алган “Подвиг Ваш бессмертен” (”Батырлыгыгыз мәнгелек”) дип аталган стенд эшләнгән. Шулай ук Боек Ватан сугышында катнашучыларнын алтмышка якын истәлекле альбомнары саклана. Шундыйлардан Слаев Фатих Хәсән улына музейда аерым почмак булдырылган. Заманында ул vзе дә «Колхозчы-ударник» газетасында мохәррир урынбасары булып эшләгән, авыл хезмәтчәннәре, авыл тормышы хакында мәкаләләр бастырган. Музейда анын фронттан язган берничә хаты саклана. Кызганычка каршы, Фатих Хәсән улы сугыштан кире әйләнеп кайта алмаган...
Гомумән, музейда һәр мәгълvмат матур һәм зәвыклы итеп эшләнгән стендларда, тобәкнен тарихын чагылдырган фотосурәтләр, язмаларда да чагыла. Шунысы да моһим, сугыш ветераннары истәлекләрен мәнгеләштерv максатыннан, Наил абый тәвәккәллеге белән авылда Әфган сугышында катнашучылар истәлегенә куелган обелиск-һәйкәл дә тозекләндерелә.
Музейда педагог, шәркыятьче галим, педагогика фәннәре докторы Мирза Исмәгыйль улы Мәхмvтовка багышланган “Герой партасы” урнаштырылган. Мирза Мәхмvтовнын шәрәфле исемнәре бик кvп, ул 18 ел Татарстан мәгариф министры булып эшләгән, бу олкәдә искиткеч зур хезмәт куйган кешеләрнен берсе. Шундый мохтәрәм шәхесләре, олпат затлары белән горурланып яшиләр Ләбәжәдә!
Ләбәжә авылы мәчетләре, анын имам-хатыйплары, могаллим-модәррисләрнен һәрберсен барлап, зур итеп чыгарылган календарьга аерым тукталып vтәсебез килә. Зур тарихны сыйдырган бу календарь ел саен чыгарылса да, артыгы булмас. Әлеге vзенчәлекле календарь кvп жирлекләргә олге булып торырлык! Стена календаре итеп эшләнгән бу ядкәр киләчәк буыннарга олпат тарихларын искә тошереп торырга, онытмаска бик зур ярдәм итәр һәм һәр авылныкы шулай эшләнсә, нинди кvркәм һәм затлы бvләкләрнен берсе булыр иде.
Музейнын бер экспозициясендә әлеге тобәктә яшәvче татарларнын мәдәниятен һәм конкvрешен гәвдәләндерә торган экспонатлар урнашкан. Бер почмакта XX гасыр татар йортынын эчке кvренеше торгызылган. Әлеге йортны Наил абый vз куллары белән эшләгән, ана килеп керv белән башка доньяга әләккән кебек буласын, һәр экспонаттан жылылык боркелә, жанга рәхәтлек инә. Башкача була да алмастыр могаен, чонки ул Наил абыйнын йорәк кушуы буенча, бар кvнелен салып эшләнгән. Тагын шундыйлардан, балалар арбасы-чыгыр беркемне дә битараф калдырмастыр. Аны да Наил абый vзе ясаган, vзе матурлаган, сурәтләр тошергән. Шулай ук натураль хужалык алып бара торган татар гаиләсенен эш кораллары да кvпторле. Ни генә юк монда: чигелгән, тегелгән кvлмәк-солгеләр, әби-бабаларыбыз кулланган эш кораллары, йон эрләv кабалары, иске язу машиналары, авыл тарихын яктырта торган язма-документаль мәкаләләр, материаллар, тимер һәм кәгазь акчалар, иске бизмән, кvкеле сәгать, самовыр, чуен vтvк, чабаталар, чалгылар, ышкылар һ.б. Туку осталыгы исә vзе генә дә кvз явын алырлык!
Безне, этнографияне ойрәнvче галимнәр буларак, музей фондларында саклана торган милли киемнәр бик куандырды, аеруча XIX–XX йоз башына караган ирләр чапаны. Шулай

ук татар-мишәрләрдә характерлы булган хатын-кыз камзулы, күлмәкләр кызыксыну уятты. Татар милләтен билгели торган кием торе булган бу камзуллар, сәнгать белгечебез Людмила Михайловна Шкляева искәрткәнчә, инде бик сирәк очрый, биредәге олгегә дә бүгенге кондә реставрация таләп ителә. Мондый экспонатлар халкыбызнын зәвыгы, кулга осталыгы хакында сойли, күнел жылысы белән эшләнгән мондый әйберләрдән затлылык анкып тора.
Музей киләчәк буынга чын мәгънәсендә тәрбия чыганагы булып тора. Укучылар очен музейда үткәрелгән класс сәгатьләре искиткеч бай тарихи мәгълүмат бирә, тарихи вакыйгаларны анларга ярдәм итә, илебез тарихына кызыксыну уята. Татар халкы тарихын ойрәнүдә музейда саклана торган авыл тарихын чагылдырган экспонатлар, фоторәсемнәр, китаплар белем һәм тәрбия бирүдә зур әһәмияткә ия. Балаларны халкыбыз тарихы, рухи казанышлары, милли үзенчәлекләре, йолалары, тормыш-конкүрешенә кагылышлы экспонатлар белән таныштыралар. Әлеге музейда уздырылган чаралар еш кына чын мәгънәсендә тормыш дәресләренә, доньяны танып-белү дәресләренә әверелә, хәтергә берегеп кала. Топ игътибар һаман да үткәннәребезнен кадерле ядкәрләре булган рухи мирасны саклау, аларны халыкка житкерүгә, тәкъдим итүгә юнәлдерелә. Мондый музейларнын эшләп килүе бик моһим. Шунысы да куандыра, Наил абый әйтүенчә, музей яна экспонатлар белән тулыланып тора, авыл халкы да бу эшкә бик жаваплы карап, үзләре күп кенә истәлекле әйберләрне фондларга тапшыра.
Наил абый кырык елдан артык үз туган тобәгенен тарихын бортекләп жыя, Мордовия, Мәскәү, Пенза архивларында, торле китапханәләрдә шогыльләнә. Шунын нәтижәсе буларак, ул – оч китап авторы.
Шунысы да бик күркәм: Наил Хәйдәр улы укучылар белән тобәк тарихын ойрәнүгә бәйле торле олимпиада һәм конкурсларда катнашып, призлы урыннар алалар. 2023 елда гына да алар Халыкара, Россиякүләм, Республика бәйгеләрендә 1 нче дәрәжә 16 диплом белән бүләкләнгәннәр.
Күргәнебезчә, фидакяр, ару-талуны белмәс кешеләр яши Ләбәжә авылында. Наил абый авылдашлары белән берлектә күп кенә проектларда катнаша. Анын эшләнәсе эшләре, теләк, максатлары әле бик күп. Ул шуларны тормышка ашыру белән янып яши. Алга таба да унышлар юлдаш булып, үз тобәге, туган авылы, Ләбәжә авылы кешеләре очен тырышкан тынгысыз Наил абыйнын башлангычлары жинү үрләрен яуласын дигән теләктә калабыз. Шундый фидакяр жаннар булганда тарихыбыз онытылмас, анын юлын дәвам итүчеләр табылыр, ышанычлы алмаш та булдырылыр. «Мен кат ишеткәнче, бер кат күрүен хәерлерәк» диләр. Музейга килсәгез, сез мона үзегез дә инанырсыз! Тагын бер кат мәктәп коллективына, Наил абыйга зур рәхмәтебезне житкерәбез!

**Әлфия БУЛАТОВА**, *филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнен ареаль лингвистика бүлегенен олкән фәнни хезмәткәре,*
**Ләйлә ГАРИПОВА**, *филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнен Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*